# КАРАР

**14 ноябрь, 2022 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокло хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Адай авылы урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Адай авылында урам юл челтәрен карап тоту (килешү буенча түләү);

- Адай авылы клубы территориясен койма белән әйләндереп алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- артезиан скважиналары өчен су насосы алу;

- Адай авылына керү һәм чыгу урыннарында видеокамералар урнаштыру;

-Адай авылында янгын гидрантларын урнаштыру,янгынга каршы җиһазлар сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина тоту;

-Адай авылында урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру;

- физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар булдыру,спорт чараларын үткәрү (булган яссылык спорт корылмаларын һәм тренировкалар өчен белгеч хезмәтенә түләү ,спорт чараларын әзерләүгә һәм уздыруга чыгымнарны каплау;

-Адай авылында сабантуй уздыру урынының территориясен төзекләндерү;

-Адай авылында су белэн тәэмин итү корылмаларын салу, су торбалары үткәрү һәм ремонтлау,артезиан скважиналары өчен тирән насос сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 342 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 177 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 177 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Адай авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны «Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Адай авылы урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Адай авылында урам юл челтәрен карап тоту (килешү буенча түләү);

- Адай авылы клубы территориясен койма белән әйләндереп алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- артезиан скваженалары өчен су насосы алу;

- Адай авылына керү һәм чыгу урыннарында видеокамералар урнаштыру;

-Адай авылында янгын гидрантларын урнаштыру,янгынга каршы җиһазлар сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина тоту;

-Адай авылында урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру;

- физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар булдыру,спорт чараларын үткәрү (булган яссылык спорт корылмаларын һәм тренировкалар өчен белгеч хезмәтенә түләү ,спорт чараларын әзерләүгә һәм уздыруга чыгымнарны каплау;

-Адай авылында сабантуй уздыру урынының территориясен төзекләндерү;

-Адай авылында су белән тәэмин итү корылмаларын салу, су торбалары үткәрү һәм ремонтлау,артезиан скваҗиналары өчен тирән насос сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727